БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

# ДУСЛЫК

КПССның ОКТЯБРЬ РАЙКОМЫ ҺӘМ ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ РАЙОН СОВЕТЫ ОРГАНЫ

ОРГАН ОКТЯБРЬСКОГО РАЙКОМА КПСС И РАЙОННОГО СОВЕТА НАРОДНЫХ ДЕПУТАТОВ

| Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №24 (7041) | 24 февраль, 1990 ел. ШИМБӘ | Бәясе 3 тиен. |
|---|---|---|---|

## Планны — срогыннан алда

НУРБ бригадалары бу көннәрдә ике айлык заданиене үтәү өчен тырышлыкларын куйлар. 11 бригаданың 6 сы аны башкарып чыкты инде.

Эксплуатация бораулавы алып баручылар арасында Р. Мингалимов җитәкләгән коллектив иң югары нәтиҗәгә ирешә. У. Газизов, М, Хәсәншин, Й. Газизов җитәкләгән коллективлар да март ае исәбенә эшлиләр. Разведка бораулавы үткәрүчеләр арасында В.Трифонов, Р. Борһанов бригадалары да икеайлык заданиене төгәлләде инде.

А. МАЛЫГИНА.

## БЕРДӘМЛЕКТӘ — БЕЗНЕҢ КӨЧ

### (Район партия-хуҗалык активы җыелышыннан)

22 февральдә КПСС райкомының утырышлар залында район партия-хуҗалык активы җыелышы булып үтте. Аның эшендә КПСС райкомы члennары һәм членлыкка кандидатлар, район партия оешмасының ревизия комиссиясе членнары, шәһәр предприятиеләре һәм оешмалары, колхозлар һәм совхозлар партия оешмалары секретарьлары, җитәкчеләре, халык депутатларының авыл Советлары башкарма комитетлары председательләре, КПСС райкомы, район Советы башкарма комитеты, ВЛКСМ райкомы аппаратлары җаваплы работниклары, сугыш һәм хезмәт ветераннары, хатын-кызлар советының район советлары членнары, мәктәп директорлары һәм аларның урынбасарлары һәм башкалар катнашты.

Актив җыелышы республикада һәм Казанда иҗтимагый-политик ситуация мәсьәләсен тикшерде. Бу мәсьәлә буенча җыелышта КПСС райкомының беренче секретаре Х. Х. Морадыймов чыкты.

Иптәш Морадыймов 18 февральдә Казанда, Яр Чаллыда, Түбән Камада, Алабугада формаль булмаган оешмалар инициативасы белән митинглар булып үтүен билгеләп узды. Митингларның ул Казанда үткәненә аерым һәм конкрет тукталды.

18 февральдә көндезге 12 сәгатьтә Казан шәһәренең Ирек мәйданында митинг оештырыла. Ул формаль яктан сайлау алды кампаниясе уңаеннан округ сайлау комиссиясе тарафыннан чакырылган итеп санала. Чынлыкта исә ул формаль булмаган оешмалар тарафыннан оештырыла. Анда 7 меңнән артык кеше катнаша.

Хәлил Хәмзиевич көн тәртибенең болай куелуының сәбәпләрен аңлата. Формаль булмаган оешмалар төрле дәрәҗәдәге Советларга сайлаулар барышында күпчелекне үз кулларына алуны максат итеп куйганнар. Сайлау кампаниясе аларның бу теләкләренең чынга ашмавын күрсәтә. Шуңа күрә алар сайлау кампаниясе барышыннан канәгать түгел, митинг оештыралар. Анда «Татарстанга — союздаш статусы», «Өлкә һәм шәһәр комитетларын — отставкага!» һәм шуңа охшаш лозунглар да була.

Оратор бу хәлгә объектив бәя бирә. Митинг барышында коммунистлар һәм формаль булмаган оешмалар вәкилләре чыгыш ясый. Һәм, әйтергә кирәк. Соңгылары йогынтысы тәэсирчәнрәк була. Резолюция кабул иткәндә дә аларның йогынтысы үзен сиздерә.

20 февральдә әлеге митинг уңаеннан КПСС өлкә комитетының чираттан тыш пленумы үткәрелә. Анда чыгыш ясаган өлкә комитетның беренче секретаре М.Шәймиев хәлгә объектив бәя бирә. Докладны тикшерүдә 20 дән артык кеше чыгыш ясый. Алар арасында партия өлкә комитетының эшчәнлегенә тәнкыйть күзлегеннән чыгып объектив бәя бирүчеләр, дисциплинаны, партия сафларын ныгыту кирәклегенә игътибар юнәлдерүчеләр, өлкә комитетының аерым секретарьларыннан отставка таләп итүчеләр, аның курсы белән килешмәүчеләр дә табыла.

Пленум тикшерелгән мәсьәлә буенча карар һәм резолюцияләр кабул итә.

Чыгышының азагында иптәш Морадыймов бүген килеп туган хәлдә район партия оешмасының бурычларына кагыла. Бер үк вакытта әлеге мәсьәләләргә карата үзенең позициясен дә ачыклап уза.

КПСС райкомы секретаре А. А. Коростелёв бүгенге ситуациядә формаль булмаган оешмалар белән эшләү, массалар арасында эшләү мәсьәләренә туктала Бу күзлектән чыгып караганда формаль булмаган оешмалар активлык күрсәтәләр. Ул алда сөйләнгән Казандагы митингның җанлы шаһиты буларак Халык фронты активистларының һәм башка формаль булмаган оешмаларның эшчеләр арасында хәйлә белән пропаганда алып бару методлары турында сөйли, аларның программаларыннан һәм башка төрле документларыннан өзекләр китерә.

Халык депутатларының район Советы башкарма комитеты председателе В. В. Богатиков КПСС Үзәк Комитеты Пленумы алдыннан 4 февральдә Мәскәүдә үткән митинг барышын күзәтүе, анда Халык фронты һәм башка формаль булмаган оешмаларның халык күңеле белән ничек уйнаулары турында үз тәэсирләре белән уртаклашты.

Х. Х. Морадыймов чыгыш ясаганда җыелышта катнашучылардан район үзәк китапханәсен шәһәр Советы бинасына вакытлыча күчереп тору мәсьәләсендә фикерләрен белдерүне сораган иде. Шуңа күрә чыгышының азагында В. В. Богатиков үз позициясен ачыклады. Шәһәр Советы башкарма комитетын район Советы башкарма комитеты бинасына күчерүгә риза түгеллеген белдерде.

Сүз уңаеннан әйткәндә, бу мәсьәлә буенча фикер алышуда катнашучыларның күбесе аңа кагылды.

(Ахыры 2 нче биттә).

## Заречныйда очрашу

22 февральдә 225 нче номерлы Биләр Озеро сайлау округы буенча ТАССР халык депутатлыгына кандидат КПСС райкомының беренче секретаре Х. Х. Морадыймов Заречный авылы сайлаучылары белән очрашты. Җыелышны авыл Советы башкарма комитеты председателе М. П. Стажарова ачты. Депутатлыкка кандидатның ышанычлысы П. Я. Генералов Х. Х. Морадыймовның биографиясе, хезмәт юлы, бүгенге эшчәнлеге белән таныштырды.

Иптәш Х. Х. Морадыймов җыелышта катнашучыларга районда сайлауларга хәзерлекнең барышы, КПСС райкомы эшчәнлегенең стиле һәм методлары турында сөйләде, күпсанлы сорауларга җавап бирде.

Җыелышта агымдагы елның март аенда район предприятие, оешма, учреждение җитәкчеләре катнашында Заречный авыл Советы территориясендә яшәүчеләр белән «ачык хатлар» көне үткәрү турында карар кылынды.

● Официаль хроника

## Яңа колхоз оешты

Күптән түгел «Россия» колхозының Каравыл Тавы бригадасы колхозчылары Рус Мәңҗесе, Каравыл Тавы авыллары, Единение поселогы составында мөстәкыйль колхоз төзү турында карар кабул иттеләр. Колхозга якташлары Советлар Союзы Герое А.И. Кузнецов исеме бирелде.

Колхоз председателе итеп «Восход» колхозында арендатор булып эшләүче В. А. Трифонов сайланды.

Җыелышта КПСС райкомының беренче секретаре Х. Х. Морадыймов катнашты һәм чыгыш ясады.

## *Кәкре Атау уңганнары*

Муса Җәлил исемендәге колхозда бозау караучыларның һәркайсы тәҗрибәле булулары белән аерылып торалар. Әлбәттә бозау карау җиңел эш түгел. Аларны кечкенәдән үк яшь баланы тәрбияләгән кебек бөтен көчеңне биреп үстереп кенә алардан артым алып була. Әнә Рокия Галимова үз группасындагы бозаулардан 832 грамм көнлек үсеш алды. Сәрфия Нурмөхәммәтова һәм Хәят Садыйкова да нәкъ шулай эшлиләр. Алар үз хезмәтләрен яратып, җиренә җиткереп башкаралар.

М. АЛИЕВ.



Миния Бикташеваның беренче товарлыклы-сөтчелек фермасында сыер савучы булып эшли башлавына ун елдан артык вакыт үтте. Шушы дәвер эчендә ул үзен уңган, тырыш савучы итеп танытты. Узган ел М. Бикташева кулдашы Н. Әбҗәлимова белән һәр сыердан уртача 3648 килограмм сөт савып алдылар. Бу уңышка ирешүдә шул ук фермада терлекче булып эшләүче ирләре Нәсибулла Бикташев һәм Газинур Әбҗәлимовның да зур өлешләре керде.

Рәсемдә: «Кондырча» махсус хуҗалык сыер савучысы Миния Бикташева.

## Аеруча активлар

«Рассвет» совхозының икенче бүлекчәсендә шәхси хуҗалыклардан сөт-май җыюда тоткарлыклар булганы юк.

Күп еллардан бирле халыктан сөт җыючылар Ибраһим Гыйззәтуллин һәм пенсионер Сәгыйть Әхмәдиев үз эшләрен намус белән башкаралар. Узган ел алар шәхси хуҗалыклардан мең килограммга якын сөт җыеп дәүләткә тапшырдылар.

Аеруча активлардан Хөсния Гыйззәтуллина, Ринат Тимербулатов, Рамил Вәлитов, Әхәт Фәйзуллин һәм башкаларны билгеләп үтәргә була. Мәсәлән, Х. Гыйззәтуллина январь аенда 13, Ринат Тимербулатов 10 килограмм май, 77 килограмм сөт, ветеринария врачы Рамил Вәлитов 95 килограмм сөт тапшырдылар.

Җиткерелгән заданиене үтәү өчен сөт-май җыю дәвам итә.

Р. РӘҖӘПОВ,
авыл Советы председателе.

## Бүгенге санда

ПАРТИЯ-ХУҖАЛЫК АКТИВЫ.
•БЕЗНЕҢ КАНДИДАТЛАР
•КӨЧЛЕЛӘР КӨЧ СЫНАША

## Эшләр әйбәт бара

«Комбайн» колхозының мөгезле эре терлек симертүчеләре өчен январь ае зур куанычлар китерде. Әйтик, икенче товарлыклы-сөтчелек фермасының Наил Ногманов җитәкчелегендәге өч кешелек аренда звеносы үзләре карый торган бер яшьтән зуррак бозаулардан 1111 әр грамм көнлек артым алдылар. Өченче товарлыклы-сөтчелек фермасыннан коммунист М. Колчурин, П. Шишков җитәкчелегендәге группаларда да хәлләр әйбәт бара.

Колхоз буенча терлекләрнең уртача тәүлеклек артымнары 776 грамм. Узган елның январь ае белән чагыштырганда 496 граммга артык дигән сүз бу.

Сыер савучылар да зур тырышлык куеп эшлиләр.

Ә. ФӘССӘХОВ,
партоешма секретаре.

## Безнең кандидатлар

# СТАНЦИЯ НАЧАЛЬНИГЫ

Тимер юлчы формасыннан йөрүче хатын-кызны вокзалда, перронда һәм станциянең йөк дворында да еш очратырга мөмкин. Махсус эмблемалары булган кара костюм һәм юбкасы аның мөлаем йөзен тагын да яктырак, сөйкемлерәк итеп күрсәтә. Ул—Норлат станциясе начальнигы Л. Н. Газизуллина.

Любовь Никифоровна бөтен аңлы гомерен тимер юлчы хезмәтенә багышлаган кеше. 18 яшьлек кыз хезмәт юлын Южно-Сахалинск тимер юлының Синегорск станциясендә дежурный булып башлый. Уссурийск шәһәрендә тимер юл техникумын тәмамлагач тормышка чыгу сәбәпле хезмәт урынын алмаштыра, Норлатка күчеп кайта. Биредә хезмәт этабының барлык буыннарын диярлек үтә: Норлат станциясендә дежурный, йөк дворында мөдир, станция начальнигы урынбасары вазифаларын башкара. 1969 елда станция начальнигы итеп билгеләнә һәм бүген дә шул хезмәттә.

Любовь Никифоровна —заман сулышын тоя белүче яңа тип җитәкче. Ул һәр мәсьәләдә, беренче чиратта, игътибар үзәгенә кешене куя. Ул үзен киң белемле, хезмәт сөючән, дисциплиналы җитәкче итеп күрсәтте, үзенә һәм хезмәттәшләренә таләпчән. Кешеләр белән уртак тел таба белә, оештыру сәләтенә ия. Ул җитәкчелек иткән чорда станция артта калучылардан алдынгыларның берсенә әверелде, коллектив күп тапкырлар күчмә Кызыл байракка һәм бүләкләргә лаек булды. Аның хезмәт кенәгәсендә 30 дан артык бүләкләү турында язу бар. Аңа «Мактаулы тимер юлчы» исеме бирелде. Ике тапкыр ул партия өлкә конференциясенә делегат итеп күрсәтелде.

Сайлау кампаниясе башлангач тимер юлчылар аны 226 номерлы сайлау округы буенча ТАССР халык депутатлыгына кандидат итеп күрсәттеләр. Аның кандидатурасын 21 предприятие коллективы яклады. Шунысы да бар, ул номенклатур күрсәтмәләр буенча түгел, эшчеләрнең үз теләге белән тәкъдим ителде. Ул үзенең принципиальлеге, эшлеклелеге һәм кешелек сыйфатлары белән сайлаучылар ихтирамын яулады. Аның абруе турында сөйләгәндә КПСС райкомы бюросы члены, күп тапкырлар район Советы депутаты итеп сайлануын әйтеп узмый мөмкин түгел.

Любовь Никифоровна тыйнак һәм намуслы. Үзенең платформасында ул районда юл төзелешен тагын да киңрәк җәелдерү өчен тырышачагына басым ясый.

Хәер, Газизуллина башка тимер юлчыларның күп проблемаларын хәл итүгә дә нәтиҗәле өлеш кертә. 1988 елда тимер юлчылар өчен торак төзү мәсьәләсендә кыен хәл килеп чыкты. Аның инициативасы һәм катнашында Мәскәүгә Транспорт төзелеше министрына бару оештырылды. Бу мәсьәләне уңай хәл итүгә булышты. Йорт төзелде, ул хәзер файдалануга тапшырыла инде. Тимер юлчылар өчен поликлиника кору да алып барыла. Яңа вокзал төзү мәсьәләсендә дә станция начальнигы ныклык һәм эзлеклелек күрсәтә. Ул берничә тапкыр Куйбышев тимер юлы җитәкчеләре белән очрашу оештыруга ирешәте һәм хәзер мәсьәлә хәл ителү стадиясендә.

Газизуллина төзелеш материаллары— торбалар, кирпеч, шифер бүлү мәсьәләсендә дә районга булышлык күрсәтә. Цемент белән кыен хәл туган очракта күп предприятиеләр һәм оешмалар аңа мөрәҗәгать итәләр. Бу мәсьәләдә дә ул кулдан килгәнчә ярдәм итәргә һәрчак әзер тора.

Аңа шәхси йомыш белән килүчеләр дә байтак. Мондый кешеләрне дә ярдәменнән ташламый. Ягулык белән тәэмин итүдә, санаторийга путевка бүлүдә, йортын ремонтлауда кулыннан килгәнчә булыша. Аның ярдәме белән икенче группа инвалид Л. Жидовкина йортына үзәктән җылыту системасы кертелде. Шундый ук эш Бөек Ватан сугышы ветераны Г. Гафуров һәм К. Глухов йортларында да үткәрелде. Хезмәт ветераннары П. Ножкинга, Н. Лаврентьевага предприятие фондыннан кер юу машиналары бүленде. Красноармейская урамында яшәүчеләр аңа су колонкасы кую мәсьәләсендә үтенеч белән килгәннәр иде. Алар да канәгать калды. Хезмәт ветераннарына, сугышта һәлак булучыларның гаиләләренә йортларын ремонтлау һәм башка мәсьәләләрдә дә ярдәм күрсәтелә. Ул һәр үтенечне җавапсыз калдырмый.

Любовь Никифоровна шәхси тормышы белән дә күпләргә үрнәк булырлык. Ире белән алар ике бала үстерделәр. Уллары политехника институтын тәмамлады инде, ДРСУ да начальник урынбасары булып эшли. Сүз уңаеннан әйткәндә, аларны юл төзүче гаиләсе дияргә дә булыр иде. Алдан билгеле булганча, Любовь Никифоровна бу мәсьәләдә районга зур булышлык итә. Ире Адлер Ибраһимович халык депутатларының район Советы башкарма комитеты председателе урынбасары буларак, шулай ук беренче чиратта бу мәсьәлә белән шөгыльләнә.

Моннан тыш гаиләдә кызлары бар. Ул да әнисе кебек тырыш, кызыксынучан, мәктәптә гел бишлегә генә укый.

Менә шундый ул безнең кандидат Любовь Никифоровна.

**Л. МОЛДАВСКИХ,**
депутатлыкка кандидатның ышанычлысы.

# Ихтыяр көче

Егоркино авылына килеп кергәч, «Россия» колхозы парткомы секретаре Тамара Жирнова сәгатенә күз салып алды.

—Хәзер Юлия Германовна өйдә булырга тиеш. Кая барабыз?

—Ихтыярыгыз,—дидем мин.

Машинабыз, колхоз фермасына печән кайтаручы тракторларны узауза, авыл урамы буйлап юлны дәвам итте.

Бу авылда күптән булганым юк иде инде. Анда зур үзгәрешләр күзгә ташлана: агач биналар урынына таштан икешәр катлы мәктәп, идарә һәм клуб салганнар. Йортларның, гаражларның да күбесе кирпечтән. Шундый йортларның берсе алдына килеп туктадык.

Юлия Германовна өйдә, кухняда мәш килә иде.

Әңгәмәбез традицион сораудан башланды, кыскача үзе турында сөйләүне үтендем.

—1952 елда Егоркино авылында туганмын. Мәктәпне тәмамлагач, бер ел Алабуга СПТУсында укыдым. Кайткач ветеринар булып эшләдем, инде менә өченче ел дуңгызчылык фермасы мөдире.

Соңрак белдем: ул хезмәтләре белән райондашларыбызга яхшы таныш Герман Алексеевич һәм Мария Гавриловна Михеевларның тугыз балаларының берсе икән. Бу гаиләдән, Юлиядән тыш, тагын дүрт туганы механизаторлар булып колхозда эшли. Хәер, Юлиянең ире Виталий Николаевич та шулай—кранчы.

Аларның өч балалары үсә, берсе дә крестьян хезмәтеннән йөз чөерми. Йорттагы мал-туарны карау күбесенчә алар җилкәсенә төшә. Ә алары шактый: сыер, кышлаган бозау, сарыклар, казлар һәм тавыклар.

Без Юлия Германовна эшләгән дуңгызчылык фермасында да булдык. Ул авыл кырыена елга буена урнашкан.

—Минем эш көнем иртә таң белән биредә башлана, —ди Юлия Германовна. —Идарәдә кичектергесез йомыш төшкәндә генә булам.

Коллектив җитәкчесенә биредә эш чынлап та җитәрлек: фермада 23 кеше эшли. 2100 баш дуңгыз һәм аларның балалары исәпләнә. Җәен бу сан яшь үрчем исәбенә икеләтә диярлек арта.

Ферма биналары чиста, җылы. Яшь үрчем өчен җылыткыч лампочкалар куелган. Үрчем 35—40 килограммга җиткәч, комплекс-автоматка симертү өчен озатыла. Ферма авыл халкын да яшь үрчем белән тәэмин итә. Үткән ел, мәсәлән, индивидуаль үстерү өчен 1026 баш дуңгыз баласы сатып бирелгән.

Юлия Германовна үзеннән бигрәк хезмәттәшләре турында иркенләп сөйли. Биредә хезмәт сөюче тырыш работниклар аз түгел. Шундыйларның берсе Ленин ордены белән бүләкләнгән Зинаида Акимовна Белова. Башка терлекчеләргә дә тел-теш тидерерлек урын юк. Мария Кадяшева, Николай Имуков, Сергей Кузьмин, Юлия Имукова, Петр Мандрейкин турында ул бик җылы фикерләр әйтә. Әле яңарак кына биредә эшли башлаган Александр Имуков турында да ул уңай фикердә.

Хезмәте барның хөрмәте дә бар. Коллективның тәҗрибәле терлекчеләре адресына колхозда мактау сүзләре еш ишетелә. Бу тармакта эшләүчеләрнең күбесе 200—240 сумга кадәр хезмәт хакы ала.

Кызганычка каршы, проблемалар да күп әле. Ферма мөдире алар турында борчылып сөйли.

—Сайлаучылар белән очрашу вакытында нәрсәләр турында сөйләячәксез?—дип сорыйм.

—Эш турында,—ди ул озак уйлап тормый тына. —Буш сүзләр берәүне дә кызыктырмый хәзер.

Беренче чиратта эш мөһим. Ансыз табын муллыгы булдыру, азыктөлек проблемасын хәл итү мөмкин түгел. Бу изге теләкне чынга ашыру—катлаулы мәсьәлә. Чөнки, дөресен генә әйткәндә, дуңгызчылык фермасына эшкә килергә кеше табу да җиңел түгел хәзер. Килгәннәре дә күп уйлап тормый китәргә әзерләр. Шуңа күрә аларга игътибар һәм кайгыртучанлык кирәк. Җитәкче буларак, Саврандейкина шуны истә нык тота. Һәм, гомумән, ул һәрчак әйткән сүзен үтәргә әзер тора. Ихтыяр көче дә җитәрлек.

**Ф. САВГАЧЕВ,**
СССР Журналистлар союзы члены.

# Яшьләргә-көндәлек кайгыртучанлык

## БЕЗНЕҢ ИНТЕРВЬЮ

**Районыбыз комсомоллары үзләренең пленумында ТАССР халык депутатлыгына кандидат итеп ВЛКСМ райкомының беренче секретаре Иван Куликовны күрсәттеләр.**

**Күптән түгел аның ышанычлысы С. Маслова кандидатның сайлауда үз алдына нинди бурычлар куюы турында берничә сорау белән мөрәҗәгать итте. Бүген без газетабызда шушы әңгәмәне бирәбез.**

СОРАУ: Иван Николаевич, сайлаучыларны беркадәр үзегез белән таныштырып үтсәгез иде.

ҖАВАП: Миңа 28 яшь. Иске Чаллы авылында туып үстем. 1978 елда, урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, ике ел буена Куйбышев шәһәрендә укыдым һәм эшләдем, шуннан ук хәрби хезмәткә чакырылдым. Чик буе гаскәрләрендә хезмәт иткәннән соң ВЛКСМ Үзәк Комитетының «Орленок» Бөтенсоюз пионер лагерына эшкә тәкъдим иттеләр. Андагы хезмәтем яшьләр белән эшләү өчен үзе бер мәктәп булды.

1983 елда, туган якларга күңел тартканга, авылга кайттым һәм Иске Чаллы урта мәктәбенә укытучы булып урнаштым. Читтән торып Казан дәүләт педагогия институтына укырга кердем. 1986 елның апрелендә ВЛКСМ райкомының укучы яшьләр белән эшләү буенча секретаре итеп сайладылар. Тагын ел артык үткәч, 1988 елның октябрендә пленум членнары альтернатив нигездә мине ВЛКСМ райкомының беренче секретаре итеп сайлап куйдылар.

СОРАУ: Иван, Николаевич, республика югары власть органына сайлана калсагыз, әлбәттә, беренче чиратта яшьләр интересын якларсыз инде.

ҖАВАП: Яшьләр оешмасы һәм комсомол работнигы буларак, әлбәттә, бу мәсьәлә игътибар үзәгендә торачак. Миңа бүген яшьләр проблемалары нинди кискен торганлыгы яхшы мәгълүм, аларны хәл итүне гомумдәүләт бурычы итеп саныйм. Яшь кешеләрнең, егетләрнең һәм кызларның, шул исәптән укучыларның да хокукларын яклау зарури. Моннан тыш, материаль яктан аз тәэмин ителгән һәм социаль яклау тапмаган категория халыкның —яшьләрнең, күп балалы һәм тулы булмаган гаиләләрнең, сугыш һәм хезмәт ветераннарының, ятим балаларның, инвалидларның, сугышчы-интернационалистларның хокукларын яклауны да алгы планга куям. Яшьләрне эш һәм торак белән тәэмин итү, шәхеснең һәрьяклап үсеше өчен мөмкинлекләр тудыру турында да конкрет кайгырту таләп ителә.

СОРАУ: Әйе, яшьләр проблемалары бүген бик кискен тора. Аларны хәл итү өчен сез конкрет ниләр эшләр идегез?

ҖАВАП: Аларны берьюлы гына хәл итеп булмый, комплекс программа эшләү мөһим. Яшьләрне үзгәртеп кору процессларына киң тарту, аларга политик ышаныч күрсәтү, энергияле яшьләрне җитәкче постларга тәкъдим итү, инициативаларын яклау, районның, шәһәрнең һәм авылларның социаль-экономик үсеш планнарын гамәлгә ашыруда советларда, хезмәт коллективлары советларында, җәмәгать һәм хуҗалык оешмаларында җаваплы постларга тарту кирәк.

СОРАУ: Платформагызда экология мәсьәләләренә кагылышлы юллар да бар.

ҖАВАП: Әйе, кеше һәм укытучы-биолог буларак та, бу мәсьәләләрдән читтә кала алмыйм, чөнки бездә дә ул бик кискен тора. Шуның өчен табигатьне саклауга саксыз караучыларга закон тәртибендә җаваплылыкны көчәйтүне тәкъдим итәм.

СОРАУ: Мин бәлки сез әйтергә теләгән теманың һәммәсен ача алмаганмын.

ҖАВАП: Бу уңайдан шуны өсти алам, мин һәр урында яшьләр фондлары булдыруны яклап чыгам. Ул средстволарны материаль ярдәмгә мохтаҗ декрет ялындагы яшь хатын-кызларга, яшьләр ихтыяҗын канәгатьләндерүгә тотарга мөмкин булыр иде.

Алга куелган бурычларны үтәү өчен теләсә нинди мәсьәлә буенча да, яшьләр белән беррәттән, гомуми интересларны күздә тотып һәм хезмәттәшләренең төрле группалары белән эзлекле хезмәттәшлектә эш итәчәкмен, чөнки бүген теләсә нинди мәсьәләне хәл иткәндә дә кеше һәм аның ихтыяҗы алгы планга килеп баса.

## *Советлар Союзы Герое призына*

**СПОРТ**

11 февральдә Иске Чаллы авылында Советлар Союзы Герое Н.К. Синдряков призына традицион чаңгы ярышы уздырылды. Иң элек аңа куелган һәйкәл янында митинг булды. Анда колхоз парткомы секретаре иптәш А. Ф. Сухов авылдашлары Н. К. Синдряков тормышы белән таныштырды, аның батырлыгы турында кыскача гына сөйләп үтте. Ярышта катнашучылар һәйкәл янына чәчәкләр куйдылар һәм бер минут тынлык урнашты.

Аннан соң ярышлар башланды. Беренче булып стартка хатын-кызлар чыкты. Алар 3 километр дистанциядә көч сынаштылар. Кызлардан «Правда» колхозы чаңгычылары арасында көрәш кызганнан-кызды. Тик Якушкинодан бер кыз гына кушылды правдалыларга. Нәтиҗәдә Ирина Белова («Правда» колхозы) дистанцияне 18 минут 02 секундта узып җиңүче булды. Татьяна Белова икенче, Якушкинодан Люда Михедюкова өченче урынга чыкты.

Хатын-кызлар арасында НГДУдан В. Демьяновага тиңнәр булмады. Ул дистанцияне 18 минут 06 секундта үтте һәм җиңүче итеп танылды. Икенче урынга Р. Кыямова (НГДУ) һәм Л. Илюхина («Правда» колхозы) өченче урынга чыкты.

Ә аннан соң эстафетаны ир-атлар алды. Алар 5 һәм 10 километр дистанциягә йөгерделәр. Яшүсмерләр арасында 5 километрга йөгерүдә В. Янилкин, Е. Попов, Н. Шартынов, А. Попов лидерлыкны алдылар.

Һәм әнә 29 номерлы Евгений Попов (Түбән Чаллы) финишка якынлашып килә. 10 километр ара артта калды. Аның вакыты 38 минут 20 секунд. Әлегә бу иң яхшы вакыт, икенче Попов— Александр финишка якынлаша, ул туганыннан 1 минутка гына калыша.

Болельщиклар 56 номерлы Николай Шартынов (Иске Чаллы) һәм Вячеслав Янилкинны (2 нче мәктәп) көтәләр. Һәм менә Янилкин финиш линиясен кисеп үтә һәм иң яхшы вакытны күрсәтә. Аның нәтиҗәсе— 37 минут 57 секунд. Н. Шартыновның вакыты 38 минут 58 секунд. Бу өченче урын. Икенче нәтиҗә Евгений Поповта.

Ирләр арасында көрәш кызыклы барды. Биредә «Правда» колхозы чаңгычысы Николай Казаковка тиңнәр табылмады. Ул дистанцияне 36 минут 39 секундта узды. Бу ун километрга йөгерүдә иң яхшы вакыт. Икенче урынны, дистанцияне 39 минут 40 секундта узып, Богдашкино урта мәктәбе директоры И. Д. Белов алды. Өченче урында физкультура укытучысы, спорт ветераны В. П Трофимов.

Командалар арасында беренче урынга «Правда» командасы чыкты. Аңа күчмә кубок тапшырылды. Икенче урында НГДУ, өченчедән Синдряков исемендәге колхоз командасы.

Ярышта җиңүчеләр һәм призлы урыннарны алучылар кыйммәтле бүләкләр, призлар, мактау кәгазьләре алдылар.

**Т. КАМАЛЕТДИНОВ.**

## Исерек килеш транспортта

Күптән түгел район эчке эшләр бүлегенең дәүләт автоинспекциясендә автотранспорт руле артына исерек килеш утыручыларны тикшерү буенча административ комиссия утырышы булды. Комиссия СССР Верховный Советы Президиумының 1983 ел 15 нче мартында чыккан «Юл кагыйдәләре җаваплылыгын көчәйтү турында»гы Указына нигезләнеп, исерек килеш транспорт йөртүче түбәндәге иптәшләрне транспорт йөртү хокукларыннан мәхрүм итте. АТП шоферы В. А. Трофимов —3 елга, районара сәүдә базасы шоферы В. С. Кәлимуллин, «Родина» колхозы тракторчысы Г. В. Герасимов, «Тәрнәс» совхозы тракторчысы Н. В. Козырьков, райпо шоферы Р. З. Гәрәев—1 әр елга транспорт йөртү хокукларыннан мәхрүм ителделәр.

«Агропроммехмонтаж» ПМКсы диспетчеры Г. М. Инякинга В. Г. Ходячевның исерек килеш транспорт белән идарә итүенә юл куйганы өчен 100 сум штраф салынды.

Комиссия транспорт йөртү хокукыннан мәхрүм ителүче кайбер иптәшләрнең җәза срогын кыскарту турында карар кабул итте. Мәсәлән, 547 нче ПМК шоферы В. А. Семочкин, XXI партсъезд исемендәге колхоз шоферы И. Х. Касыймов һәм башкаларга транспорт йөртү хокукы яңадан кайтарылды.

**Ринат Мөхәммәдиев**

# БАРЫ ТИК БЕРЕНЧЕ

**хикәя**

**(Дәвамы. Башы 21—22 саннарда).**

—Чыгымчылап тора, иенә китерәм, —булды җавап. Аны танысалар да ул бу агайны үзе танымый иде. Хәер, Фәләхов бит районда билгеле кеше.

—Үз атың булгач, беләсеңдер инде, — дип килгән юлыннан китеп барды агай. Аны-моны аңламады.

Фәләховка да китәргә генә иде дә бит. Ләкин җаны тынычланмаган иде шул әле аның. Тагын ниндидер карарга килеп ул кесәсенә тыгылды һәм аннан нәни генә пәке чыгарды... Башта ул авызлык турыннан ике яклап та йөгән каешын кисте, аннан, ияр булмаганлыктан ат сыртына малай үзе ясап куйган киез бавына җитеште. Ат сбруеның җаен ул яхшы белә, шуңа күрә каешларны бөтенләй үк кисеп чыгармады.

Һәм, ниһаять, Фәләхов иркен сулыш алып, елтыр бияне тагы бер ялгызы калдырып китеп барды. Ә атның үз хуҗасы—урман каравылчысы малае бу вакытта ике кулына ике морожный тотып чираттан чыгып килә иде. Район сабантуеның ямьлелеге, гармун һәм җыр авазларыннан, чабышка әзерләнгән атларның матурлыгыннан башы әйләнгән чагы иде шәһәргә бу җәйдә беренче тапкыр килеп чыккан малайның. Аңардан да бәхетле кем булды икән шул мизгелдә.

x x x

Ат чабышында катнашучылар мәйдан белән янәшәдә генә старт сызыгына тезелделәр. Елтыр кола бия беренчеләрдән булып килеп басты. Аның әледән-әле пошкырырга итенеп, уңлы-суллы башын чайкавын сыртына менеп атланган малай яхшыга юрады. Атналар, айлар буе яңакларыннан сыйпап, ялларын, койрыкларын тарап, үз кулларыннан ашатып-эчертеп тәрбияләде ич ул аны. Борын тишекләренә килеп тыгылган кан тәерләреннән атның сулышы кысылуын һәм шуңарга үрсәләнүен ул ничек башына китерә алсын?

Фәләхов исә Чемпионга атланып килгән җайдагына ышанмады. Старт сызыгына чыккач кына, малайны куып төшереп, ат сыртына үзе менеп кунаклады. Чабышкылар белән таныштырганда: «Узган елгы сабантуйда җиңгән Чемпионда районыбызның алдынгы колхозын җитәкләүче Мостафа Фәләхов үзе!» дип, бу фактка аерым игътибар юнәлттеләр. Фәләхов горур гына баш какты. Мәйдан дәррәү кул чапты.

Чабышкысын елтыр кола бия янәшәсенә китереп бастырды Фәләхов. Малай исә моны искә дә алмады. Атлар гына, нидер аңлашкандай, иске танышлар буларак берберенә карангалап алдылар. Чемпион тик торган җирендә берөзлексез тынгысызланып тоякларын биетте, ә кола бия исә, сыртында бармакларын ялаштырып утырган малайга нидер әйтергә теләгәндәй, каерылып-каерылып башын болгады, авызлык тимерен чәйнәде.

—Әйдәү, кузгалдык, егетләр,хәерле сәгатьтә,— диде башына чигүле кара түбәтәй, өстенә аклы буйбуй күлмәк кигән агай.

Шуны көтеп кенә торган Фәләхов ике аягы белән берьюлы атының касыгына төртеп куйды һәм дуамалланып кинәт йөгәнен уңга, елгыр кола биягә таба тартты. Ярсып алга томырылам дигән бия, каршысында тау булып калыккан чабышкыдан читкә тайпылырга теләп, арткы аякларына үрә басты. Җайдак малай, атын тыя төшәргә чамалап, кулына урап тоткан йөгәненнән белән ат аяклары арасына шуып төште. Ни булганын аңлый да алмый калды ул.

Чабышкылар артыннан өермә булып тузан гына күтәрелеп калды. Урман каравылчысы малае күзләренә тулган кайнар тамчыларны яшерә алмый мышык-мышык борынын тартып, кола бия артыннан китеп барды. Авыртудан, сызланудан түгел, шул тикле кеше карап торганда ат өстеннән егылып төшү гарьлегеннән иде булса кирәк аның яшьләре.

Мәйдан күздән югалганчы ат белән малай, сүз берләшкәндәй, иелгән башларын күтәрмәделәр. Бер-беренә карамый гына янәшә атладылар. Яңа гына булып узган күңелсезлектә алар икесе дә кемне дә булса башка берәүне түгел, үзләрен, бары тик үзләрен гаепле саный иделәр шикелле. Дөньяда көнчелек, мәкер дигән төшенчәләр булуы хакында һәм кайберәүләрнең минминлекләренә хуҗа була алмый, үзенекен итү, шәхси максатына ирешү юлында теләсә нинди чарадан да чирканмый эш итәргә сәләтле икәнлеген алар каян белсен? Җәй башының шушы матур иртәседәй чаклары иде ич әле аларның.

Малай утын Ушмы суы буйлап салынган киң такыр юлдан түгел. коры елга читләтеп урманга таба әйдәде. Чабыштан кайтучы атларга каршы очрамас өчен шулай итте ул. Узыш дәрте белән онытылып томырылып чапкан атларны, ат ялына сеңгән җайдакларны күрмәс өчен әллә нигә дә риза иде ул. Бәгырьләренә утырган җәрәхәткә тагы бер кат тоз салудан кемгә файда...

Малай адымнарын тизләтте. Кола бия дә калышмады. Алар һаман, мәйданнан ничек чыгып киткән булсалар, шулай янәшә атлыйлар иде. Атка менеп юыртып китеп бару турындагы уй башына да килеп карамады малайның. Ул да түгел, ат һәм малай икесе берьюлы диярлек артка —су буена таба башларын бордылар. «Тупыртупыр» килеп тояклар биешә иде анда. Чабышкылар кайта. Иң алдан, башка атларны ким дигәндә дүрт-биш дилбегә буе ара калдырып, Чемпион томырыла. Мәйданга да аның шулай беренче борып керәчәгенә шик юк. Әнә ич, ничек җиңел чаба—кушаяклары җәядән ычкындырылган укмыни —атлап түгел, очып бара.

Сабырлыгы җитмәде, түзә алмады, ахры, елгыр биянең тынгысыз җаны. Бөтенләй көтмәгәндә-уйламаганда ул башын югары чөеп, кешнәп җибәрде. Аның кешнәү авазы шундый саф һәм әчкерсез иде ки, нигә тиңләргә дә белгән юк. Айлы кичтә вак ташлар өстенә чылтырап аккан чишмә тавышын да, бер гөнаһсыз сабыйның кычкырып көлгәнен дә, буй җиткән кыз чәчләрендә чылтырашкан чулпылар авазын да хәтерләтә сыман ул. Тагын да кешнәде елгыр бия.

Атны тынычландырырга омтылып, аның муенына сарылган малай шул чакны мәйданга илтүче юлда ниләр булганын күрми дә калды. Кешнәү авазын ишетүгә үк иң беренче барган ат кинәт адымнарын тыя төшеп, киң такыр юлдан урманга таба борылырга итте. «Чемпион... Чемпион... нишләвең бу, Чемпион?!» —дип бар көче белән йөгәнне юлга каерды җайдагы. Ат аны тыңларга теләмәде, авызлыгын чәйни-чәйни күбек чәчеп, алгы аяклары белән һаман читкә сикерде. Җайдак ике үкчәсе белән атның кабыргаларын төйде, урманга таба каерылган яклап уч төбе белән хайванның күзенә китереп сукты. Ул гына да түгел, арттан куа килгән чабышкылар бер-бер артлы үзләрен узып китә башлагач, үз-үзен белешмичә, чыбыркы сабы белән уңлы-суллы төя башлады ул атын.

Ә айгыр барыбер үзенекен итте, чыгымчылап, әле арт аякларында гына калып үрә сикерде, әле көтелмәгән кискен хәрәкәтләр ясап арт санын югары чөяргә кереште. Ни эшләргә, тагы нәрсә кылырга белмәгән җайдак чыбыркы сабы белән чираттагы кизәнүләренең берсендә җиргә очып төшкәнен сизми дә калды. Шуны гына көткән айгыр башын болгый-болгый урманга таба сузылган коры елгага төбәп чабып китте...

Ялларын җилгә тараткан кола бия җәт-җәт атлап үзе аңар каршы килә иде инде.

**Казан, 1985 ел.**

---

Хафизов исемендәге колхоз идарәсе, партия һәм профсоюз комитетлары колхозның элеккеге баш зоотехнигы

КАСЫЙМ ИСМӘГЫЙЛЬ улы ИДРИСОВның

вафат булуын тирән кайгы белән белдерәләр һәм мәрхүмнең гаиләсенең, якыннарының тирән хәсрәтен уртаклашалар.

---

«Дуслык» газетасы редакциясе коллективы радиотапшыру эшләрен оештыручы Г. М. Хәлиуллинаның әнисе

ВАЛЕНТИНА НИКОЛАЕВНА АФАНАСЬЕВАның

үлүе сәбәпле аның һәм гаиләсенең тирән кайгысын уртаклаша.

---

**РЕДАКТОР Ә. У. АБДУЛЛИН.**

**«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000. Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.**
**ТЕЛЕФОННАР: редактор—2—12—14, 2—22—81, редактор урынбасары һәм җаваплы секретарь—2—10—44, рус теленә тәрҗемә буенча редактор урынбасары—2—14—16, чуваш теленә тәрҗемә буенча редактор урынбасары —2—15—63, агропромышленность бүлеге—2—22—51, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.**

**Газетаны Фидания Хәйретдинова җыйды. Рима ГАНЕЕВА верстка ясады. Наталья ЛУКОЯНОВА басты. Корректор—Зөлфия Вәлиева.**

**Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТАССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.**
**Күләме—1 басма табак. Заказ 24. Тираж 3,867.**